| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.02.2021 Балык Бистәсе ш.т.п. №27пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 5 августындагы 203пи номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына ( балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе уртак коллегиясенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча беркетмә йөкләмәсен үтәү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 5 августындагы 203пи номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 маендагы 79пи номерлы, 2016 елның 8 июнендәге 85пи номерлы, 2017 елның 18 октябрендәге 277 пи номерлы, 2018 елның 17 августындагы 202пи номерлы, 2019 елның 18 августындагы 279 пи номерлы, 2020 елның 6 февралендәге 19пи номерлы, 2020 елның 27 мартындагы 69 пи номерлы 2020 елның 5 августындагы 153пи номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) 2.1 пунктны түбәндәге эчтәлекле «и» абзацы өстәргә:

"и) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар,

җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында салым органының белешмәсе".

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе И.М. Садиковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов